СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
30 июль, 2026 ел № 90

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, ай саен һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 25 апрелендәге 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына хезмәт хакы түләү һәм акчалата бүләкләүләрне, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары, ай саен һәм башка өстәмә түләүләрнең күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 25 апрелендәге 220 номерлы карарына (23.09.2020 №4, 12.11.2021 №122, 31.03.2022 № 156, 12.10.2022 № 212, 21.11.2022 № 225, 28.06.2024 №418, 09.10.2024 №446, 30.04.2025 №517, 12.12.2025 №23, 29.12.2025 № 29 белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Контроль-хисап органы рәисенә хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» 1 нче кушымтасының уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ел саен түләүле отпуск бирелгәндә елга бер тапкыр бер мәртәбә түләнә торган түләү муниципаль район башлыгына ике айлык акчалата бүләкләү күләмендә, муниципаль район башлыгы урынбасарына, депутатларга, контроль-хисап органы рәисенә бер айлык акчалата бүләкләү күләмендә түләнә.»;

1.2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре» 2 нче кушымтасында:

1) Таблицаны түбәндәге эчтәлекле 10 юл белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| 10. | Муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе | 26 916 |

2) Таблицаның 10-12 юлларын тиешенчә 11-13 юллары дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталы рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов